СОВЕТ СРЕДНЕКИРМЕНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
МАМАДЫШСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ул.Ленина, д.16А, с. Средние Кирмени,
Мамадышский район,
Республика Татарстан, 422171

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МАМАДЫШ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ УРТА КИРМӘН АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

Ленин ур., 16А нчы йорт, Урта Кирмән авылы,
Мамадыш районы,
Татарстан Республикасы,422171

тел.(факс): (85563) 2-92-38;2-92-44 e-mail: Skimer.Mam@tatar.ru, www:mamadysh.tatarstan.ru

---

Карар　　　　　　　　　　　　　　　　　　Решение

№ 1-44　　　　　　　　　　　　　　　　18 нче сентябрь 2019 ел

## Референдум уздыру инициативасы турында

«Россия Федерациясе гражданнары сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» 2002 ел, 12 июнь, 67-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясы, «Россия Федерациясендә жирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 ел, 6 октябрь, 131-ФЗ номерлы Федераль законның 22, 56 статьялары, «Жирле референдум турында» 2004 ел, 23 март, 23-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 12 статьясы, «Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районының Урта Кирмән авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 11 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Урта Кирмән авыл җирлеге Советы КАРАР КАБУЛ ИТТЕ:

1.Түбәндәге сораулар буенча җирле референдум үткәрү инициативасы белән чыгарга:

«Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Урта Кирмән авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган гражданнарга, 1 һәм 2 группа инвалидлар, Бөек Ватан сугышы һәм хәрби хәрәкәтләрдә катнашкан ветераннар, Бөек Ватан сугышында һәм хәрби хәрәкәтләрдә катнашканнарның тол хатыннары, 90 яшьтән өлкәнрәк гранданнар, күп балалы гаиләләр, көндезге бүлектә белем алучы студентлар, Россия Армиясе сафларында хезмәт итүчеләрдән кала, 2020 елда 400 сум күләмендә үзара салым кертелүгә һәм ул акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен тотылуына сез ризамы:

- Арташ авылы Карл Маркс урамы буенча юлга вак таш җәю (сатып алу, ташу, вак таш җәю, килешү буенча эш өчен түләү);
- Арташ авылы урам утлары, яктырткычлар, махсус җиһазлар сатып алу, урнаштыру(килешү буенча эш өчен түләү);
- Урта Кирмән авылындагы чишмәләр территорияләрен төзекләндерү (павильон урнаштыру, махсус техника ярдәмендә чишмә үзәнен тирәнәйтү, юлын вак таш белән җәю);

- Урта Кирмән авылында юлларны кардан чистарту.

« ӘЙЕ » « ЮК »

2. Әлеге карарны авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында, Мамадыш муниципаль районы mamadysh.tatarstan.ru сайтында, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru.) урнаштырырга.
3. Әлеге карарның үтәлешен Мамадыш муниципаль районы Урта Кирмән авыл җирлеге башлыгы Б.Ф.Хәсәновка йөкләргә.

Мамадыш муниципаль районы
Урта Кирмән авыл җирлеге башлыгы,
Совет председателе Б.Ф.Хәсәнов